■ Әхлак

ТӘҮБӘ

Тәүбә - гарәп сүзе, “таба” дигән фигыльдән алынган, кайту дигән мәгънәне белдерә.

Адәм баласы тормышта хата-кимчелекләрсез яши алмый. Нинди генә ялгыш адымнар ясамасын, гөнаһ кылмасын, әлегә тормыш рәвешен хәерлегә әйләндерү, Аллаһ кушканча яшәргә отылу, “туры юлга” кайту тәүбә дип атала.

Тәүбә ике төрле була.

Беренчесе - бәндә белән Аллаһ Сөбехана вә Тәгалә арасында кылынган гөнаһ өчен тәүбә. Адәм баласы Аллаһ хакын үтәмәсә, бу вакытта тәүбә итүнең өч шарты бар: беренчесе - кальб белән үкенү, икенчесе - тел белән истигъфар (дога вә зекер) кылу, өченчесе - Аллаһ каршында башка бу гөнаһны эшләмәскә сүз бирү. Өч шартны үтәгән вакытта, берәр фарыз гамәле төшеп калып, аңа каза кылынмаган булса, тәүбә кабул ителми.

Икенчесе - бер кеше белән икенче кеше арасында кылынган гөнаһ өчен тәүбә. Бу гөнаһның сәбәбе, әйтик, кеше хакын үтәмәү, аны җәберләү, кыерсыту, малын урлау, канын кою, дәрәҗәсен төшерү булса, алда әйтеп үтелгән өч шартка - ягъни үкенү, тел белән истигъфар кылу, бу гөнаһка кире кайтмаска сүз бирү шартына рәнҗеткән кешедән гафу үтенү дә өстәлә.

Соңгы вакытта “Динле булсаң, булмасаң да, намаз укысаң, укымасаң да, адәм баласы барыбер гөнаһлы” дигән сүзләрне еш ишетергә туры килә.

Хакыйкатьтә, дөньяда гөнаһсыз адәм баласы юк. Әмма Аллаһны таныган бәндә белән Аллаһны танымаган бәндә арасында аерма бар. Иманлы, Аллаһ Сөбехана вә тәгаләне таныган бәндәнең фазыйләте шунда ки, әгәр дә үз гомерендә гөнаһ вә хата кылса, аның ялварып сорар Раббысы бар. Имансыз, Аллаһны танымаган бәндәнең гөнаһсыннан тәүбә итәр, сорар заты бармы,

Бөек Аллаһтан башка кылган гөнаһларыбызны гафу кылучы һичбер зат юк, булмас та! Адәм баласы, фәрештәләр, табигать тә - һичнәрсә бу кодрәткә ия түгел. Фәкать Аллаһ Сөбехана вә Тәгаләнең туксан тугыз исеме арасында шундый исем вә сыйфаты бар: Ул - Гафар (гөнаһларны гафу кылучы), Ул - Тәввав (тәүбәләрне кабул итүче).

Тормышта кеше теге яки бу гөнаһны ялгышып кына да эшләргә мөмкин. Тик бүгенге көндә адәм баласы ялгышып кына калмаган, Аллаһны онытырлык дәрәҗәдә гөнаһ эченә кереп чумган, әлегә гамәлләреннән арынырга, тәүбә кылырга аның теләге юк. вакыты җитми.

Шуны онытмайык, һәр гөнаһ кальбтә карап тап калдыра, ә һәрдаим гөнаһ кылу кальбнең “каты”лануына һәм тагын да каралуына сәбәпче була. Кеше үзе моны сизми, “пенсиягә чыккач, тәүбә кылырмын да, Аллаһ кушканнарны үти башлармын”, дип тыныч кына җан асравын дәвам итә.

Әйе, бүген бик күпләребез, үлем турында онытып, хыял дөньясында яши. Югыйсә, үлем - янәшә. Иртән йокыдан уянганда, кич җитүен күрә алырбызмы, кигән киемебезне үзебезгә салырга насыйп булырмы яисә бу гамәлне мәет юуучының куллары башкарырмы, өйдән чыгып киткәндә, чираттагы адымыбыз ниятләгән урыныбызга илтерме, әллә кабергәме - белмибез! Үлем һәркемгә дә якын, һәм шул ук вакытта ул мәңгелек мәсьәләсен хәл итүче Җәннәт белән Җәһәннәмгә күчеш чоры булып тора...

Җәһәннәмдә кешеләрнең иң күбесе “мусаввифун”нар булуы мәгълүм. “Мусаввифуннар”ның кем икәнен беләсезме, Алар - “Тәүбәгә килергә, Аллаһ кушканча яшәргә өлгерербез әле”, - дип әйтүчеләр.

“Монафыйклар” сүрәсенең 9нчы аятендә: “...сезне малларыгыз һәм балаларыгыз Аллаһ зекереннән алдамасын, намаздан туктатмасын һәм Коръән белән гамәл кылудан гафил итмәсен.

Әгәр бу эшне берәү кылса, андый кешеләр Ахирәттә газапта булып хәсрәтләнүчеләр”, - дип кисәтелгән.

Әмма “Әгәр тәүбә кылып, намазларын үтәсәләр һәм зәкятләрен бирсәләр, алар диндә сезнең кардәшләрегездер”, - ди Аллаһы Тәгалә.

Дөньяда тәүбә кылырга хакы булмаган адәм баласы юк. Бу эш пәйгамбәрләрдән башлап, иң гөнаһлы бәндәләргә кадәр гомум. Аллаһы Тәгалә Коръәндә: “...һәммәләрегез дә Аллаһуга тәүбә итегез, шаять, дөнья вә ахирәттә бәхетле булырсыз”, - ди.

ВӘХШИ

Мәккә кәфере Вахши ибн Хәрби өһүд сугышында Пәйгамбәребез (с.г.с.)нең туганнарыннан булган батыр сәхабә Хәмзәне һәлак итә. Әлегә батырлыгы өчен оста укчыны коллыктан азат итәргә вәгъдә кылалар...

Өһүд сугышы бетеп, берничә ел вакыт узгач, Мәккә шәһәре кәферләр кулыннан азат ителә. Вәхшигә качып, котылудан башка чара калмый. Ул Таиф шәһәренә яшеренә.

Вакыйга болай гына тәмамланмый. Вәхшинең Ислам динен кабул итүе хакында тарихта ике риваять бар. Беренчесендә, Аллаһның Рәсүле янына, аның пәйгамбәрлеген танып, ул үзе килгән, дип, икенчесендә, Пәйгамбәребез (с.г.с.) аңа Исламны кабул итәргә өндәп хат язган дип сөйләнә. Вәхши исә Мәккәгә баручылар артыннан әлегә хатка җавабын да юллаган: “Әй Мөхәммәд, минем исламга керү ниятем бар, әмма моннан мине “Фуркан” сүрәсенең: “Вә алар Аллаһудан башкага гыйбадәт кылмаслар һәм Ахирәт өчен Аллаһудан башкадан ярдәм сорамаслар, Аллаһ үтерүне харам иткән кешене үтермәсләр, мәгәр үтерергә тиешле булса гына үтерерләр, вә зина да кылмаслар, әйтелгән шул ярамаган эшләрне берәү эшләсә, гөнаһының җәзасына ирешер” дигән 68нче аяте тыеп тора”. Хатның ахырында: “Мин шушы аятьтә мәзһүр ителгән өч гөнаһның өчесен дә кылдым, синең иң якын туганың Хәмзәне дә үтердем, минем кебек кеше гафу кылыныр мы?” - дип тә өстәгән.

Пәйгамбәребез (с.г.с.) аңа: “Әгәр дә берәү тәүбә итеп, иман китерсе һәм Коръән юлы белән изге гамәлләр кылса, әнә шундый кешеләрнең начарлыкларын яхшылыкка алмаштырыр, Аллаһ андыйларга ярлыкаучы вә рәхмәт кылучы булды”, - дип “Фуркан” сүрәсенең 70нче аяте белән җавап кайтара.

- Бу аятьтә “изге гамәл кылу”дигән бер шарт бар икән, аңа минем кодрәтем җитәрме, - дип борчылуын белдерә Вәхши.

Моңа җавап рәвешендә: “Аллаһ Үзенә тиңдәшлек кылуны гафу итмәс, тиңдәшлек кылудан башка гөнаһларны Үзе теләгән кешедән гафу итәр...” - дип, “Ниса” сүрәсенең 48нче аяте иңә.

- “Йә Мөхәммәд, бу аятьтә “Аллаһ барча гөнаһларны теләгән бәндәсенә генә кичерә”дигән шарт та бар...” - ди Вәхши.

Моңа җавап итеп. Пәйгамбәребез (с.г.с.) “Зүмәра” сүрәсенең 53нче аятен язып җибәрә: “Минем мөэмин бәндәләремә әйт: “Ий бәндәләрем, гөнаһ кылып, үзегезгә зарар иткән булсагыз, Аллаһуның рәхмәтеннән өмет өзмәгез, чөнки тәүбә итеп төзәлгәндә, Аллаһ бөтен гөнаһларны ярлыкаучы, Ул Аллаһ - ярлыкаучы вә рәхимледер”.

Вәхшидә башка сорау тумый. Һәм ул Мәдинә шәһәренә килеп, ислам динен кабул итә...

КЫРЫК КӨН ВӘ КЫРЫК ТӨН

Көннәрдән беркөнне Пәйгамбәребез (с.г.с.) янына Гомәр (р.г.) килеп керә. Күз-ләрендә яшь бөртекләре күреп, Пәйгамбәребез (с.г.с.) аннан: “Йә Гомер, нигә елыйсың?” - дип сорый. “Йә Рәсүлуллаһ, Синең ишегең төбендә бер яшь егет басып тора, - ди Гомәр р.г., - тормыш хәлен сөйләп, мине борчуга салды”.

Егетне үзе янына чакыртып керткәч, Пәйгамбәребез (с.г.с.) аннан ни өчен елавының сәбәбен сорый. “Йә Рәсүлуллаһ, олуг гөнаһларыма Аллаһның газабы килүеннән куркып елыйм”, - дип җавап кайтара егет.

- Әллә син Аллаһка ширек китердеңме, - ди Пәйгамбәребез (с.г.с.).

- Юк.

- Берәр кешене хаксызга үтердеңме?

- Юк.

- Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә кичерәдер гөнаһларны, хәтта ул гөнаһларың җиде кат күк, җиде кат җир, биек таулар хәтле булса да... - ди егеткә Пәйгамбәребез (с.г.с.).

- Йә Рәсүлуллаһ, минем гөнаһым җиде кат күк, җиде кат җир, биек таулардан да зуррак...

- Әллә синең гөнаһың Аллаһның гаршеннән дә зурмы,

- Әйе, - ди егет.

- Әллә синең гөнаһың Аллаһның гафуыннан да зурмы,

- Йә Рәсүлуллаһ, Аллаһ һәр нәрсәдән зур һәм бөек...

- Сөйлә гөнаһыңны, - ди Пәйгамбәребез (с.г.с.).

- Йә Рәсүлуллаһ, сезнең каршыда бу гөнаһымны сөйләргә оялам...

- Сөйлә...

- Йә Рәсүлуллаһ, мин җиде елдан бирле каберләрне талап йөрим. Бу кәсебемнән, бәлкем, бер дә тыела алмаган булыр идем... Күптән түгел Мәдинә сәхабәләреннән бер яшь кыз вафат булгач, каберенә килеп, аны ләхетеннән чыгардым. Кәфенлеген ачып, бер байлыгын да күрмәгәч, кире борылып китәргә уйлаган идем... Шул вакыт иблис мәлгунь вәсвәсә кылды... Һәм мин киткән җиремнән кире борылып, мәет кыз белән зина кылдым... Тиз генә зираттан чыгып китәргә иде исәбем, әмма бу кыз телгә килеп: “Мәетләр диярында гаурәтемне ачып, Аллаһ каршында минем белән зина кылдың. Кыямәт көнендә “үч алучы көн”нән курыкмыйсыңмы?” - дип сорады. Нишләргә белмәгәннән синең тарафыңа килдем йә Рәсүлуллаһ...

Кулын бу егетнең җилкәсенә куеп: “Җәһәннәмгә синнән дә лаеклырак кеше юк...” - дип, Пәйгамбәребез (с.г.с.) аңа кырык көн вә кырык төн ихлас күңелдән тәүбә кылырга куша...

Кырыгынчы төн тәмамланганнан соң, егет Раббысыннан ялварып сорый: “Йә Раббым, тәүбәмне кабул иткән булсаң, Үзеңнең Рәсүлең Мөхәммәд Мостафа (с.г.с.)гә һәм аның сәхабәләренә бу хакта хәбәр бирсәң иде. Гөнаһымны кичермәгән булсаң, Ахирәт газабыңнан куркам, ут җибәреп, яндыр мине”.

Шул вакыт Җәбраил г.с. Пәйгамбәребез (с.г.с.)гә егетнең гөнаһысы кичерелүе хакында шатлыклы хәбәр китерә.

Кырык көн вә кырык төн...

Әлбәттә, тәүбә гөнаһ микъдарында булырга тиеш. Әмма, кайбер галимнәрнең фикеренчә, тере кеше белән зина кылу мәет белән зина кылуга караганда күпкә гөнаһлырак икән...

Әйе, гөнаһ кылу биек кыядан зур ташны төртеп төшерү кебек бик җиңел. Әмма тәүбәгә килү - ошбу ташны биек кыяга күтәрүгә тиң...

БӘЛГЕНЛЕККӘ ТӨШКӘН КЕШЕ

Пәйгамбәребез (с.г.с.) көннәрдән беркөнне үзенең сәхабәләреннән: “Бу өммәттә бәлгенлеккә төшкән кеше кем?” - дип сорады. “Аллаһ һәм Аның Рәсүле белүчерәк”, - диделәр сәхабәләр. “Бу өммәтнең бәлгенлеккә төшкән бәндәсе шулдыр, - диде Пәйгамбәребез с.г.с., - Кыямәт көнендә ул килер намаз, ураза, изге гамәлләре, хәтта Хаҗлары белән, әмма кемнедер рәнҗеткән, гайбәтен сөйләгән, бәндә белән бәндә арасын бозган, дәрәҗәсен төшергән, канын койган, малын урлаган булса, Аллаһ Сөбехана вә Тәгалә кыерсытылган кешеләргә мөрәҗәгать итеп: “Сезне кыерсыткан кешенең теләгән изгелеген алыгыз”, - дип әйтер. Әлегә кешенең укылган намазы, тотылган уразасы, кылган Хаҗы, изгелеге алынып беткәннән соң, бер яхшы гамәле дә калмаса, кыерсытылган кешеләргә Аллаһ Сөбехана вә Тәгалә: “Инде хәзер бу бәндәгә үзегезнең гөнаһыгызны бирегез”, - дип боерыр...”.

Әгәр дә кешене кыерсытсак һәм аннан гафу сорамасак, Кыямәт көнендә иң бөлгенлеккә төшкән кешеләр рәтендә булырбыз икән...

ХИКМӘТЛЕ КАРТ

Бәни Исраил кавемендә бер патша яшәгән. Көннәрдән беркөнне аңа якын-тирәдә бер хикмәтле карт яшәве турында хәбәр иткәннәр. Патша бу мөэминне сараена чакыртып китергән дә: “Син миңа бик кирәк, кергәләп йөр. Каксаң, ишегемне ачарлар”, - дигән. Бу хикмәтле карт патшадан: “Кереп йөрермен. Әгәр дә синең өеңдә мин берәр көнне ярдәмче кызыңны белән шаярсам, моңа ни диярсең?” - дип сораган. Патша ачуланып әйткән: “Әгәр дә мин сине шундый гамәлендә күрсәм, капкама якын да китермәм”. “Минем Бөек Затым бар, - дигән хикмәт иясе. - Көнгә җитмеш мәртәбә гөнаһ кылсам да, Ул миңа ризык, һава, нигъмәт ишеген япмый...”.

Бу хикмәтле картның сүзендә зур мәгънә ята!

Хакыйкатьтә, намаз укымаса да, ураза тотмаса да, гөнаһ кылса да, Аллаһы Тәгалә нигъмәтен һичкемнән кызганмый. Ул һәрберсенә дә Рәхимле. (Кешеләр генә аңламыйлар бу нигъмәтеңне, йә Раббым!) Әмма Аллаһ Сөбехана вә Тәгаләнең туксан тугыз гүзәл исеме арасында бер исем бар, Ул - Муаххир, ягъни гөнаһка җәзаны азакка чигерүче. Газабын шул ук секундта бирми, бер көн, атна, ай, ел яки гомеребез буена тәүбәгә килүебезне көтә. Аңлыйсызмы?! Тирә-юнегездә бозык, динсез, имансыз бәндәләрнең хәере вә сәламәт тормыш белән яшәүләрен күрсәгез, “Аллаһ бу кешене җир йөзендә ничек тота микән?” дип аптырамагыз, Раббыбыз аның да үлгәнче тәүбәгә килүен, хакыйкый юлга кайтуын көтә...

Кояш мәгърибәтен калыккач, кешеләр: “Карагыз, карагыз, мәгърибтарафына, кояш калка” дип кычкырырлар икән. Шул вакытта җир йөзендәге һәрбер адәм баласы Кыямәт көне килүен аңлап, тәүбәгә вә сәждәгә егылыр...

Тик тәүбәләр кабул кылынмас...

“Тәүбә ишеге җаныгыз бугазыгызга терәлгәнче ачык”, - диде Пәйгамбәребез (с.г.с.).

Аллаһ Сөбехана вә Тәгаләдән хаталарыбызны, гөнаһларыбызны кичерүен исән чагыбызда ук ялварып сорыйк. Гөнаһларыбызның гафу ителүен телибез икән, үзебез дә гафу итүчеләрдән булыйк...

“Дөреслектә Аллаһ тәүбә итеп төзелүчеләрне һәм күңел, тән нәҗесләреннән пакьләнүчеләрне сөядер”.

“...Ий Раббыбыз, безгә нурыбызны тутырып бир һәм гөнаһларыбызны ярлыка, Син һәрнәрсәгә кадирсең!”.

“Ий Раббым, мине вә мөэминнәрне ярлыка вә рәхмәт кыл! Син рәхмәт итүчеләрнең иң хәерлесе!”.